| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 11 2021 № 376

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне яңа редакциядә раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013, № 44-ФЗ Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау хакында» 18.05.2015, № 476 карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу системасын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне яңа редакциядә расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау турында» 23.12.2016, № 1716 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы Аксубай
муниципаль районы Башкарма
комитетының 25.11.2021 № 376
карары белән расланган

**Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләр**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге документ «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013, № 44-ФЗ Федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» 18.05.2015 , № 476 карары нигезендә эшләнгән әлеге документ (алга таба - № 476 карар), Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актларын эшләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба - таләпләр) билгели, раслый:

а) муниципаль органнар, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре;

б) муниципаль органнар, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан товарларның аерым төрләренә, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләре;

в) муниципаль органнар, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

г) муниципаль органнар, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан товарларның аерым төрләренә, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) карата таләпләр.

## 2. Хокукый актларны кабул итү һәм үзгәртү

2.1. 1.1 пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән хокукый актлар норматив хокукый актлар (муниципаль хокукый актлар) проектлары рәвешендә эшләнә

2.2. Таләпләрнең 1.1 пунктындагы «в» һәм «г» пунктларында күрсәтелгән

хокукый актлар проектлары мәҗбүри булырга тиеш

Башкарма комитет каршындагы муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышларында (алга таба - Комиссия) алдан фикер алышу

2.3. Таләпләрнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хокукый актларны иҗтимагый тикшерү максатларында фикер алышуны үткәрү өчен, сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә карата Гомуми таләпләрнең 6 пункты нигезендә, күрсәтелгән хокукый актлар проектлары һәм аларга аңлатма язуы, аларны әзерләгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми порталында (алга таба - Сайт) урнаштырыла.

Таләпләрнең 1.2 пунктының 1, 2 абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар сайтта «Сатып алулар» бүлегендә урнаштырыла.

Таләпләрнең 1.2 пунктындагы 3 абзацында күрсәтелгән хокукый актлар җирле үзидарәнең тиешле органы Сайтында, битендә урнаштырыла.

2.4. Җәмәгать контроле максатларында фикер алышуны үткәрү вакыты сайтта таләпләрнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын урнаштырганнан соң җиде календарь көн тәшкил итә.

2.5. Җирле үзидарә органнары гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, электрон яисә язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен, таләпләрнең 2.4 пунктында билгеләнгән срокта карый.

2.6. Җирле үзидарә органнары иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен караган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге тәкъдимнәрне һәм җавапларны сайтка урнаштыралар.

2.7. Иҗтимагый контроль максатларында, кирәк булганда, иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен исәпкә алып, комиссия утырышларында хокукый актлар проектларының 1.1 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрен исәпкә алып, үзгәрешләр кертү турында Карар кабул ителә.

2.8. Таләпләрнең 1.1 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хокукый акт проектын эшләп бетерү зарурлыгы турында;

б) хокукый актны кабул итү мөмкинлеге турында.

2.9. Комиссиядән хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында бәяләмә алынган очракта, җирле үзидарә органнары әлеге проектны, комиссия кисәтүләрен исәпкә алып, өч эш көненнән дә соңга калмыйча эшләп бетерәләр һәм аны кабат комиссиягә җибәрәләр.

2.10. Комиссиядән уңай бәяләмә алган очракта, җирле үзидарә органы хокукый акт проектын раслый.

2.11. Комиссия кабул иткән карар, тиешле карар кабул ителгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайтта урнаштырыла.

2.12. Расланган хокукый актлар сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында аларны раслаганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

2.13. Таләпләрнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хокукый актларга үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырылырга мөмкин:

2.13.1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан муниципаль берәмлек бюджеты турында Карар кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү;

2.13.2. товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга планлаштырылган күләмне һәм бәясен үзгәртү;

2.13.3. гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка очракларда.

2.14. Таләпләрнең 1.1 пунктындагы «в» һәм «г» пунктчаларында каралган хокукый актлар җирле үзидарә органнары тарафыннан елына кимендә бер тапкыр карала.

## 3. Хокукый актларның составы һәм эчтәлеге

3.1. Муниципаль органнар, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен раслаучы район Башкарма комитеты карары Гомуми таләпләрнең 4 пунктында каралган мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

3.2. Район Башкарма комитеты муниципаль органнар, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслаучы карарында Гомуми таләпләрнең 5 пунктында каралган мәгълүмат булырга тиеш.

## 4. Хокукый актларның үтәлешен тәэмин итү

Муниципаль органнар, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) таләпләрне раслаучы муниципаль хокукый актлар нигезләмәләрен һәм (яки) районның муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар үтәүне тикшерү муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг барышында гамәлгә ашырыла.